ЯШЬ ШАГЫЙРЬНЕҢ БЕРЕНЧЕ КИТАБЫ

БИКӘ
РӘХИМОВА

СӘРВИНАЗ

Бикә Рәхимова Татарстанның Әлки районы Чуваш-Кичүе авылында туган. Күрше авыл — Түбән Әлкидә урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетына укырга керә. Университетны тәмам итеп, китапханәче, укытучы була. Хәзерге вакытта Татарстан китап нәшриятында эшли.

Авторның шигырьләре «Социалистик Татарстан», «Яшь ленинчы», «Вечерняя Казань» газеталарында, «Казан утлары», «Ялкын», «Совет мәктәбе», «Волга» журналларында, «Идел» альманахында, «Кызлар җыры» исемле коллектив җыентыкта басылдылар.

Яшь шагыйрьнең беренче китабы

БИКӘ
РӘХИМОВА

СӘРВИНАЗ

Шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
1986

ББК 84.5(2Р-Тат.)
Р 88

Өлкән яшьтәге мәктәп балаларына

Рәхимова Б. Р.

Р 88 Сәрвиназ: Шигырьләр.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1986.— 64 бит.

Авторның беренче китабында матурлык, батырлык, намус, мәхәббәт, бәхет, туган илне, туган төбәкне ярату турындагы шигырьләре урын алды.

Р $\frac{4803010 2-008}{М132(03)-86}$ 155—86 ББК 84.5.(2Р-Тат.)

© Татарстан китап нәшрияты, 1986

I. МОҢ КОЛАЧЫ

Алып Муса

Балачакта
Оренбург далаларын
кечкенә гәүдәсе белән
тутырып яшәгән Муса:
клубында — Муса,
түгәрәктә — Муса,
бергәләшеп театр куя,
комсомолда — Муса,
яңалыкның нигезен коя.
Юк, кыска буйлы түгел,—
бәләкәйдән Алып Муса.

Мәскәвендә,
Өзлеп көткән Казанында
дусларының күңелләрен
тутырып яшәгән Муса.
Заводларда — Муса,
операда — Муса,
гасырлар бәйләнешен тоя,
легенданы Муса
халык күңленә уя.
Юк, кыска буйлы түгел,—
яшь башыннан Алып Муса.

Туган илнең
дошманына каршы,
күкрәгенә үч тутырып,
яшендәй яшьнәгән Муса.
Дәһшәт-яуда — Муса,
ут уртасында — Муса,
алда упкын, артта кыя...
Тоткынлыкта Муса...
Төрмә кысан, кысан...
Шартлап ярыла зиндан —
Алып гәүдәсе Моабиткамы сыя?
Юк, кыска буйлы түгел,—
Һәлакәттә дә Алып Муса!

Зур мәйданда,
күз алдында,
күз иркәләп
басып тора
Алып Муса.

Илгә кайткан.

Кошлар юлга артык әйбер алмый

Кошлар юлга артык әйбер алмый,
ала бары көчле канатын.
Көчле канат кына үтеп чыга
упкын-океаннар арасын.

Кошлар юлга артык әйбер алмый,
ала янга газиз баласын.
Туган якны сиземләве канда,
сизем әйтә кая барасын.

Кеше юлга артык әйбер алмый,
ала бары кирәк-ярагын.
Кош канаты җитмәс җиргә җитә —
кеше белә юлның азабын.

Кеше юлга артык әйбер алмый,
ала бары газиз дигәнен.
Моң-көйләре, кайгы-шатлыклары —
кая куйсын үзенә тигәнен?

Яшьлегемдә калам

Ләззәтле еллар ул яшьлек:
елауларның яшертене,
көлүнең чыңлап торганы,
көйләрнең җырлап торганы
ул бары тик яшьлектә.

Уенчак еллар ул яшьлек:
кояш җыйган алтын алма,
күңелләрне ымсындырып,
балкып бара, балкып бара.
Бу бары тик яшьлектә.

Газаплы еллар ул яшьлек:
үзеңә ышанмаулар,
ул күңел утырмаулар,
үз-үзең белән даулар,
ул дөнья белән даулар...

Яшьлектә
сыналган чаклар була,
сынаган чаклар була,
сынаткан чаклар була...

Сөелгән чаклар була,
сөймәгән чаклар була,
сөелмәгән чак була...

Яшьлектә
җилкәгә аласы йөкне
көчең җитеп, күтәрә алу
беренче кат сынала,
үз җегәрең дөрес үлчәү
яшьлекнең
башында ук сорала.

Авырдыр, бәлки, яшьлектә.
Әмма,
«Яшьлегемә кире кайтыр идем»,— дип,
юкка түгел җырлаулар.
Шуңа булыр,
мин яшьлегемдә калам.

Карап карыйк, ни чыгар...

Җайдак малай җыры *

Очып киләм ат өстендә:
атым минем җил төсендә,
дала гына кар төсендә —
атым чаба бар көченә.

Дала киткән ерак, ерак,
кар сибелә — гел ак, гел ак.

Очып киләм ат өстендә:
атым минем нур төсендә,
дала гына яшел төстә,
кояш көлә миннән өстә.

* Шамил Шәрифуллин музыкасы.

Яшел болын хәтфә кебек,
рәхәтләнеп ауна төшеп.

Очып киләм ат өстендә.
Атым минем — якын дустым
йөзеп чыга суны ишеп,
елга кала җырлап-көлеп.

Тыңлыйм иелеп, колак куеп —
елга кала җырлап-көлеп.

Җырлап киләм ат өстендә,
туймыйм бер дә ил гизүдән,
җайдак малай җыры булыр:
ишетсәгез кичен-иртән.

Җырым китсен илләр буйлап,
кайтсын кире иңләп-буйлап.

*«Алтын капка»га * баргач*

(Этюд)

Алтын капка —
алтын балдак
зөбәрҗәт дулкын
бармагында.

Дулкын уйный
балдак киеп.
Берсе килә,

* Кара диңгез эчендәге капкасыман кыя. Кояшта алтын төсендә булып күренә.

кия, сала,
китеп бара.
Икенчесе килеп җитеп,
киеп ала.

Уйный дулкын,
уйный диңгез!

Карап тора
югарыдан
көнләшеп,
шаккатып,
авыз ачып
«Иван Разбойник»,
«Бака», «Дөя»,
«Шайтан бармак» *.

Кырым җире

Эльбрусның итәгенә басып,
башны чөеп, өскә карыйм:
Кавказ тавы ай-яй текә!

Кырымда мин йөрим,
яссы таулар күзлим,
Кырым тавы — күркәм-иркә.

Апшеронның дуамал җиле,
ул буйсынмас,
юлына син куйма киртә.

Бөдрәләрне җайга тарый,
Кырым җиле — назлы-иркә.

---

* Кыя исемнәре.

Ташны ташка орып аккан
тау елгасы — Кавказ күрке.

Ә Кырымның серле типкән
чишмәләре — сабыр-иркә.

Купшы гөлләрне син
Кавказдан эзлә,
бердәй көяз — кайсын гына өзмә.

Кара тауның итәгендә алсу
Кырым гөле — нәфис-иркә.

Мулдан сибә кояш нурын
Кавказ иңенә.
Бу якларга суык килә өркеп кенә.

Кара диңгез дулкыннарын
бишек иткән
Кырым кояшы — рәхәт-иркә.

Куе кызыл,
Куе сары, ак-сары —
мозаика — Кавказ җире.

Куенында изге ташлар
саклап яши —
Халыкларның күңел төбе
Кырым җире...

Дербент

Дербент, Дербент*,
мифик шәһәр,
таш кала.
Үзе капка,
капкага бай:
Урта капка, Кече капка, Олы капка**.
Үзе тагын
капка капкасы.
Булган шуңа
Кавказ капкасы.
Дербент, Дербент
йөрәкләргә капка булса да,
дошманнарга капка түгел,
изге шәһәр,
чишмәләре изге, диләр.
Изге суда юыналар,
алып китәләр.
Юынгачтын
баласызлар... бала көтәләр,
авырулар терелеп китәләр.
Дербент кала,
и, таш кала,
калды синдә
кояшлы истәлек.
Кояш шундый зур синдә:
җәлпәкләнеп күккә җәелгән,
күк зәңгәрдән күчеп,
кояш төсен ала,
уйный комда бала-чага...
Дербент кала —
тимер капка,

---

* Дербент — капка-ишек (фарсыча).
** Шәһәрнең шул исемдәге капкалары булган.

таш кала,
әкияттә калган кала.
Килеп керер күк
таш урамга
таш коймасын,
тимер ишек-капкасын
барлау өчен
Анушервань* үзе.
Гаскәр белән,
ат уйнатып,
тузан туздырып.

Юлга чыксаң

Юлга чыксаң,
юл азабын бүлешергә,
булсын янда юлдашың.
Юлчыларга юлдаш булсаң,
юл йомгагың сүтелгәндә
уңнан булыр юл башың.
Еракларга юлың китсә,
күз күреме җитәр җирдә
булсын алда юлбашчың.

Җиңел кулдан

«Башла, кызым, җиңел кулдан,
чыга күрмә туры юлдан».—
Хәтеремдә, әнкәй озатты
мәктәпкә дип, тотып кулдан.

---

* I гасырда яшәгән, Дербент шәһәрен салдыручы шаһ.

Изге эшне башлаганда
әйтелә икән: җиңел кулдан.
Төшендем мин, үсә төшкәч,
аера белгәч уңны сулдан.

Фатиханы явыз җаннар
алмый уңнан, ала сулдан.—
Явыз эшләр дә кылына
җиңел генә, җиңел кулдан.

Күзем текәп артка карыйм —
балачаклар үткән, киткән.
Явыз эшне җиңел кулдан
кылдырмаска вакыт җиткән.

*
* *

Син, хурлык,
Саклап торасың да
адәм баласын
аяк астында мыштым гына,
(Абынмасмы, абынмасмы?)
бар теләгең —
Ягылыр идең син йөзенә,
шуышып кына, тын гына.

Ә аннан
байрак кебек җилфердәр идең —
Тик сине күрсеннәр генә!

Ә син, хурлык, беләсеңме,
кем сиңа аяк чала?—
Сиңа юлыккан кеше
гомерлек сабак ала.
(Акылы булса!)

*
* * *

Җир йөзендә
һөнәр төренең
исәбе-хисабы юк.

Күпмесенә
мин кызыгам,
ымсынам күпмесенә.

Ә шулардан
сихерләгәне —
бакчачы.

Күз алдында кара җирдән
яшел шытым
төртеп чыга.
Менә — беренче сабак,
менә — беренче яфрак,
менә — беренче чәчәк!
. . . .
Яшеллеккә күмелде дөнья.

Шул яшеллек җир гомренчә
торсайде.
Күңеленнән һәрбер адәм
аз булса да,
ай, бакчачы булсайде!

Балык чистартканда

Көмеш тәңкәләр
тыгыз тәннән
очып чыга,
очып чыга.

Тупырдыйдыр кебек балык
кул астымда.
Пычак тоткан көе сискәнеп
карап торам.

Ай, уңайсыз хәтта балык кына,
җансыз ятса да алдыңда.

Күңелемне күренмәгән
корыч куллар
кысып тора.

*
* *

Ашыйсым килде —
ризыкландым.
Эчәсем килде —
сусавым бастым.

Җир ашата,
Җир эчертә.

Күз алмадай
саклап тотсаң,
безнең Җирдән дә
яхшы җир
юктыр әле
Галәмендә.

Ә кеше ашкына читкә...

*
* *

Үз өлешен кызганмыйча,
дусты белән бүлешә алган —
һич шик юктыр,
ул бәхетле.

Якыннарын бәлаләрдән
йолып кына кала алган —
һич шик юктыр,
ул бәхетле.

Күңел нурын тирә-юньгә
балкып кына сибә алган —
барыннан да
бәхетлерәк.

Бу турыда кем бәхәскә
керер икән?

Моң колачы

Илһам Шакировка

Киң тавышы сәхнә-залга
сыймый,
китеп бара урман, кырына.
Кайтаваздай урап кире
кайта,
халык җанын кушып
җырына.

Халкының шатлыгыннан
алып
кайгысына хәтле күңленә
сыйган.
Якты яздай күңеле киң —
Моң колачы килә
шуннан.

*
* *

Җиргә генә ятып
елаган җилне
кем күтәреп алып
юаткан?

Бозлы тамчыларын чәчеп,
үрсәләнә диңгез,
кочагына кереп,
кемнәр җылыткан?

Буй-буй гына сыгылып
җырлый камыш,
сагыш-җырдан аны
кем тыйган?

Сыр-сыр гына булып
сибелсә дә, комнан
аркан-җепләрне соң
кем ишкән?

Әкиятләргә кереп,
хыялландырган абага —
аның чәчәкләрен
кем күргән?

Булмастай гына эшләр
булгач,
ташка орып булмый
башны ла.

Шулай булулары, бәлки,
яхшы да.

*
* *

Галәмгә омтыламы кеше,
әгәр сере булмаса?

Офыкларга күмеләме,
әгәр сере булмаса?

Еракtагы ут ник тартсын,
әгәр сере булмаса?

Төнбоеклы күл дә тартмас,
әгәр сере булмаса.

Шарлавык шаккатырамы,
әгәр сере булмаса?

Йөрәк йөрәккә тартылмый,
әгәр сере булмаса.

Кеше — ябалдашсыз агач,
әгәр сере булмаса.

Сере китсен үзе белән,
кешелекле булмаса.

*
* *

Тып-тын гына таң туды.
Бу көн өчен тагын тынычсыз тудым.
Таң тәрәзгә якты куйды.
Хисем түгел, уемны да
өлгегә куялмадым.

Монда — сукмак, анда — инеш,
ерак түгел тау ята.
Табигатьтә тәртип барсы —
хәтта күнчелек уята.
Табигать бөртөге — кеше
көйсезлектән җан ата.

*
* *

Кешеләрне мин кызганып
Еладым сәгать, сәгать:
Җанны шайтанга саталар,
Табып вак-төяк сәбәп.

Билгеле инде, үзләренчә
Ул сәбәп вактан түгел.
Акча, власть — реаль әйбер,
Янәсе, шайтан түгел.

Ялт-йолт итеп, шарт-шорт итеп,
Яшәгәндә ялтырап,
Яңгырдай күз яше түгеп,
Тора читтә җан елап.

Әнием яшьлеге

(Төш-баллада)

Урман юлы. Ике авыл арасы.
Ат юырта. Һава — хушбуй.
Яшь кияү белән кәләшкә
барасы да барасы.

Артык рәхәт. Баш әйләнә...
Сандугачлар. Кәккүк саный...
Тик нигәдер кияү менә
борылып карый, карый...

Ә тагын бер борылышта
Кияү төшә... Сүзсез китә...
Иелеп, юл биргән агач
Яфрак-яулыгын селкә...

...Яшь хатын уянып китә,
Йөрәге убылып тибә...
Иртән яудагы иренең
үлем хәбәре көтә...

Ленинград фронты. 1943 ел. Соңгы хат

Ленинград фронты. 1943 ел.
Соңгы хат.
Ә фашист приказ бирә:
Ат! Ат!
Хат язылa соңгы кат,
Соңгы кат.
Биш баласы кала.
Бәлки, килә җиде ят,
Җиде ят.
Солдат!
Туфрагыңда тыныч ят.
Тыныч ят.
Илең булды азат.
Азат!
Балаларың күрмәде газап.
Билгесез рухың — аларга гүя канат,
Канат...
Канат...

Һәркөн иртән көнчыгыштан
сызылып-сузылып таң ата.
Бәхил бул, ата.
Бәхил бул, ата.

Ленинград фронты. 1943 ел.
Соңгы хат.
Саргайган —
Гүя сары ат.
Сары ат...
Канатлы ат...

Яхшылык кылдыңмы?

Бүген яхшылык кылдыңмы?
Нәкъ менә бүген?
Әллә, иртәгә дидеңме,
тарайтып күңлең?

Теләгәннең бик күбесен
хәл итеп булмый.
Ә бит яхшылык эшләүдән
беркем дә тыймый!

Нигә иртәгә диярgә?

*
* *

Кайчак
артык тәмле сүзләр дә
туйдыра,
бик тәмле ашлар да
туйдыра,

җаннан якын ярлар да
туйдыра.
Табигатьнең яшел күзе ачык —
һич туйдырмый ул гына...

*
* *

Баллы-татлының тәмнәрен
тиңләп була туган телгә.
Ачы сүз дә якын кебек,
әйтелсә ул туган телдә.

Бәйрәм дә бит бәйрәм булмый,
рухың синең җилкенмәсә.
«Үткәннәрдән ваз кичмәгез»,—
әйтерсең лә бер җил дәшә.

«Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген»,—
Тукай язган илгә дәшеп.
Үткәрик без бәйрәмнәрне
гомер шулай бергәләшеп.

Балалар белән Кырлайга Тукай музеена бару

Чыр-чу килә бала-чага,
анда чаба, монда чаба.
Кырлайның урманыннан шүрәлене
кем алдан таба —
шул инде исәп-чама.

Чү! Менә тынды бала-чага.
Алар Тукайга чәчәк сала.
Зыңлый тынлык,
Тукайның аяк очында
тюльпан гүя үрләп яна.

Тукайның аяк очында
тюльпан яна.

Шүрәлене күрү иде
бәтен чама...

*
* *

Бала күңеле — ак кәгазь.
Атадан балага күчә,
анадан балага күчә —
балага күчә киләчәк.

Уйларыбыз күчә балага,
эшләребез күчә балага —
шулар шытым бирәчәк.

Уебыздан яхшырак булалмый,
сүзебездән яхшырак булалмый,
үзебездән яхшырак булалмый —
яхшырак булалмый бала.

Сүзебездән үзебез яхшырак,
үзебездән үзебез яхшырак,
эшебез уебыздан яхшырак —
яхшырак булу сорала.

Кирәк түгел дидактика
үгет, вәгазь белән тулы.
Ата-ана үрнәк булу —
тәрбиянең дөрес юлы.

Бала-ана кайгысы

Ачы хәсрәткә төшерә
баланың бер кайгысы.
Шәрә калган юкә агачы —
елап ята кайрысы,
Менә шундый ана-бала
кайгысы.

Ирексездән ялварасың,
билгесез көчне эзләп.
Йөрәк ачык, каның тама,
җанда бетү тойгысы.
Менә шундый ана-бала
кайгысы.

*
* *

Туганым абый — этием кебек,
Аңа карагач, күңелем тыныч.
Бәхетле язмыш — ир-ат язмышы —
Кыз туганнарны яклаучы кылыч.

Төсләр

Кышлар килә безгә ак төстә.
Яз — зәңгәргә буйый доньяны.
Җәй — без яраткан яшел төстә.
Көзен тагын сары чолганды.

Ак төс — карт төс — уйларга сала.
Зәңгәр илтә хыял иленә.
Яшел безгә тынычлык бирә.
Сары — сахра сагыш җиленә.

Бер-берсенә каршы шул төсләр,
бер җепкә лә, бергә тезелеп,
алып бара безне дә бәйләп,
Чылбыры нык... китми өзелеп...

Тартышса да төсләр дүрт якка,
бергә бәйләнгән шул тезгене.
Адәм җаны — син аккош бит,—
Галибанә булгач, түз инде.

*
* *

Дер-дер килмәгез,
нервлар,
чиртмәгез, чиртмәгез
тартылып.
Сез әле, сез әле
бары тик сизәсез,
алдагы
алышны-тартышны.

Сезме соң белмәгән,
сизмәгән
сездәге көчләрнең
ныклыгын, зурлыгын.
Сезнең бу калтырау,
Тартылу —
кош канат яргандай,
әзерлек
алдагы көннәргә,
көрәшкә.

Мин беләм,
мин тоям,

ышанам:
Җирне дә күчәре түгел лә,
сез тотып торасыз тарттырып.
Һәм бер дә санамыйм сүземне
әйтәм дип тарттырып-арттырып.

Гаепләү

Урамның уртасында,
соры асфальт өстендә
кан эчендә эт баласы:
машина таптап киткән.

Саклап тора үлгән иптәшен,
китми дә, курыкмый да,
икенчесе — исәне.
Бер машиналарга,
бер кешеләргә
карап өрә.

Шулай көчле гаепләүче
бер судья да булалмас!

Үз урыны

Яшәде өйдә
кешеләр белән бергә
бөдрә йонлы,
түгәрәк кенә
ак эт.

Ә беркөнне кимерде
диван читен.
Хуҗа гафу итмәде,
эт урамга куылды.

Башка гади
көчекләр белән йөри,
сикерә.
Йоны каралып бетте,
койрыгы шиңде.
Ә шулай да үз урнын
тапты:
хәзер ул да ректә.

Әгәр берәү

Әгәр берәү
борынын чөйсә,
элеп куярлар
шул борынга
бер җилән,
пальто-мазар.
Шулай итеп,
ул борын
чын үз урнын табар.

*

* *

Мәче-тычкан уены
«уен» гына булса да,
мәчегә генә кызыклы.

*
* *

Тәрәзәләреңдә ут яна —
Минем күңелем кабынды.

Алсын иде

Һәр кеше —
яшь чагыннан
үзе бер тәгълимат.
Шул тәгълиматның
чынлыгын
тормыш тикшерә башлый.

Алсын иде шундый бәһа һәр кеше:
вәт бу чикләвек төше!

Кызлар

Машинадан төштеләр,
чыркылдашып көлделәр.
Чыкты киндер сумкадан
иннек-иршән, көзгеләр.

Юкса, иген төйиләр,
бизәнмәсә дә, бәлки,
ярый кыр ыстанында,
Әлки дигән авылда.

«Кызлар — кайда да кызлар»,
Диләр дә, күңел әйтә:
Юк, болары особый —
уңганнар икеләтә.

*
* *

Бизәнә, хатын-кыз бизәнә.
бизәнә дә ясана.
Бар булган гәүдә-торышны
үзгәртеп азаплана.
Болай булып туган инде,
ә ул алай итмәкче;
күңелендә туган сурәтне
җан өреп тергезмәкче.
«Каш ясыйм дип, күз чыгарып»
куйган чаклары була,
үҗәтләнеп, сер бирмичә
тагын «яңадан туа».

...Сәнгатьнең озын гомере —
ир-атның даны микән?
Әллә беренчел урыны —
хатын-кыз җаны микән?

*
* *

Хатын-кыз өчен чит түгел,
чит түгел ирек сөю.
Чит булса булыр — кешедән
ирегеи өстен кую.

Хатын-кыз ирек алса да,
бәһасе кыйммәт торыр.
Үзиркен * булган хатынның
бәхете китек булыр.

* Башбаштак, үз дигәнен генә эшләүче.

* * *

Үсмер чакта, инде күптән,
кояш чыгар-чыкмас вакыт
уята да мине әни:
— Кызым, алып кайт чәй суы
каз аягы Чирмешәнгә
тигәнче,— ди.

. . . .

Ярдан баксам,
оя-оя казлар йөзә.
Ай-яй, бигрәк уңганнар!
Әллә инде төнен кунганнар?

Казлар, канатларын җәеп,
очып китәләр.

Канат-көянтәмне җәеп,
хыялымда мин дә очам
казлар белән.

Хыялый булдым.
Рәхмәт шул казларга.
Рәхмәт көянтә-чиләккә.
Рәхмәт әниемә —
иртә таңда уятканга.

Сабан туе *

Борынгыдан: бабайлардан,
әбиләрдән йола килә.
Сабан туе — уртак бәйрәм —
Халык гөрли, уйный, көлә.

* Шамил Шәрифуллин музыкасы.

Яшь киленнәр чигү чигә —
Бүләк җыю өйдән-өйгә.
Уйнак атта яшь егетләр —
Гармун күчә койдән-көйгә.

Мәйдан гөжли, көрәш кыза,
Кем җиңелә, кемнәр җиңә.
Бәйгеләрдә атлар чаба,
Алмачуар алдан килә.

Монда уен, монда көлке.
Гармун уйный, җырлап бирче.
Тыпыр-тыпыр биеп китче,
күңелгә нур өстәп китче!

Кубыз, гармун бергә сыза,
Дәртләндереп бер көй кыза.
Гадәт бетми, бәйрәм үтми —
Гасыр арты гасыр уза.

Борынгыдан: бабайлардан,
әбиләрдән йола килә.
Сабан туе уртак бәйрәм —
Халык гөрли, уйный-көлә.

Көз көнендә

Сары бодай, сары арпа, сары кавын —
Табигатьнең нигъмәтләре — гүя алтын.

Уйлар тыгыз, җылы, якты «алтын көз»дә.
Тормыш бөтенлеге хисе туа бездә.

«Алтын көз» дән «ак кышлар»га күчә килә —
Соры күктә соры болыт авыр йөзә.

Уйлар баса, күңлең булса сыңар гына;
Күк ачылыр. Табигать ул сынар гына.

Авылда иртә

(Этюд)

Иртә таңнан кояш белән
бергә тордым.
Мөгрәп узды сыер көтүе.
Урам якка гына күз салыймчы диеп,
рәхәт икән чыгып китүе.

Урам күллегендә инде кош-корт халкы.
Казлар китә зуррак инешкә.
Кай арада торган үрдәк балалары —
Чебен аулый килә-килешкә.

Карт тирәктән парашюттай карга төшә,
Аннан чума кире оя-куышка.
Ябык мәче үзе белгән разведкага бара,
Шәүлә булып җирдән шуыша.

Чык ялтырый —
Көн аяз һәм җылы булыр.
Игенчеләр инде басуда.
Җир шатлыгы белән яшәвемне тойдым
Кыр ягына аяк басуга.

Туган илгә кайттым

Үзгәргән,
Туган яклар үзгәргән,
танымаслык нигез-йортлар;
баеганнар,
зурайганнар,
киңәйгәннәр.

Тик үзгәрмәгән крестьян эше —
элгәргечә мең башлы —
берсе бетте дигәндә,
икенчесе калка.
Үткәннәрне искә төшереп,
чүп утадым,
төбенә өйдем авыл гөле —
бәрәңгенең.

Әни каберен зиярәт итү

Чәчең йолык,
башың бәр —
берни үзгәрмәячәк,
терелми бер үлгән.

Үзеннән-үзе килә сабырлык:
Туфрак катламы аркылы да
тынычландыра икән әниләр...

*
* *

Авылда җәйге кич — моңсулык,
моңсулык.
Йолдызлар, сары ай белән
сөйләшү.
Табигать бишеге эчендә
тирбәлеп,
мәңгегә икең бер тонга
көйләшү.

Шәһәрдә җәйге кич — чуарлык,
чуарлык,
Тәэсирләр күп — буа буарлык.
Ник бер төс күренсен,
табылсын
арыган җаныңны куярлык!

Әниләргә

Сезнең күңел якты —
йолдыз кебек.
Сезнең күңел чиста —
саф чишмә.
Бу дөньяда сездәй
кешеләр булгач,
тормыш суын ничек соң эчмә?!

Сезнең фидакарьлек,
сезнең бирелгәнлек,
бу дөньялар көйле барсынга! —
Үрнәк итеп алып бирер идем
бөекләрнең барсы-барсына.

Әкият дәвам итә

Көрәзәче, тылсымчылар,
кыр иясе булырлыклар,
урман телен белүчеләр,
нәкъ үтәли күрүчеләр —
болары изге көчләр.

Бозучылар, сихерчеләр,
бозыклыклар сибүчеләр,
биздерүче-бөтичеләр —
болары кара көчләр.

Ибне Сина *, Гашыйк Фәрһад,
Тагын, тагын... Исәнбәте —
Алар эшен безгә әле
исәпләсе, исәпләсе.

Бомба ясап куркытучы,
ирекне буып торучы,
алга хөсетлек куучы,
ялган лозунг кычкыручы —
Кара көч әле дә бар.

Дөньяның үлчәве шул ук:
Я яхшылык, я явызлык.
Берсенә бирсен кыюлык,
Берсенә тиеш авызлык.

Изге тылсымчылар бара да —
сихерчеләр төшә эзгә.
Шул алыштан читтә калмау —
Менә ни кирәк безгә!

*
* *

Мәңгелеккә калу өчен,
мәңге дә бер үлмәс өчен,
үлем суын эчмәс өчен,
Зөлкарнәен ** эзләп йөргән —
мәңге суның эзенә төшкән...

Легенданы тудыручы
тагын берәү — Фәрһад булган,
түземлеге гүзәл булган.

---

* Әбүгалисина.
** Зөлкарнәен — Александр Македонский.

Мәңге суны эзләп тапкан —
үлми калган.

Фиргавеннәр-падишаһлар
ник бер үләргә теләсен!
Мәңге яшисе иткәннәр —
пирамидлар күтәрткәннәр,
киптереп коллар җелеген.

Мәңге суын эчүчеләр
аз булмаган, күпләп алар —
шагыйрьләр булган, батырлар,
хезмәтчән зур халык булган.

Әгәр мин дә эзенә төшсәм,
мәңге суын эчәр идем
Фәрһад булып.

* * *

Тормыш мине тарткалады, сузгалады,
тегендә, монда этәрде.
Төрле җирдә, төрле төштә
булдым, төрле эштә.
Тик күңелем бер урында,
бер уңайга эшләде:
җисмем, хиссемне яктылыкка,
яхшылыкка өндәде.

Сабырлык көче белән

Сабырлык,
сабырлык,
сабырлык
кирәк дөньяга.

Сабырлык,
сабырлык,
сабырлык
кирәк миңа да.

Яхшылык,
яхшылык,
яхшылык
булган чагында,

Яманлык,
яманлык,
яманлык
тулган чагында,

чишелсен,
чишелсен
мәсьәлә
яхшылык ягына.

Сабырлык,
сабырлык,
сабырлык
көче белән.

Үземнән,
үземнән,
үземнән
чыгып беләм.

* * *

Гомернең уртасы җитте —
башлыйкмы яңабаштан?

Елга юлын үзгәртә дә,
ага башлый яңабаштан.

Ил тормышын үзгәртә дә,
яши башлый яңабаштан.

Искене себереп түккәч,
төзи башлый яңабаштан.

Яңаны башлау бик ярый,
кирәк икән яңабаштан.

Юл авырлыгы куркытмый,
башлыйк әле яңабаштан.

Җан тартмаса, кан тартсын

Җанның һәрчак сизгерлеген
Яклыйбыз без һаман да.
Тик әйтәләр кайчакта:
«Җан тартмаса, кан тарта».

Афәрин! Кан сизгерлеге
безнең тәннәрдә артсын.
Туганнарны туганлыкка
җан тартмаса, кан тартсын.

Минем бу газиз эшемдә
кан тартсын һәм җан тартсын.

Поэзия логикасы — тормыш чынлыгы

Якты көн кебек якты
бу шигырь,
болыты аңа булганча керер,
Туфаның алып, давыллар килгәч,
шигырь — киң күңел —
сыгылып килер.

Умырзая чәчәгенә

Үтә күренмәле таҗ яфрагың:
аксыл-шәмәхә төсләр уелган,
көнлек гомереңне сүндермәскә
килсә икән кодрәт кулымнан!
Чык суларын эчеп үсәр чәчәк —
яз башында күзең ачкансың.
Нәфислекнең көчен исбатларга,
карны тишеп, өскә калкасың.

II. АЙ ЯКТЫСЫНДА ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬЛӘР

*
* *

Энҗе тешләр,
зәңгәр күзләр:
акка төшкән
зәңгәр бизәк.

Әллә әбиемнең
кыз чагы?
Әллә әниемнең
кыз чагы?
Әллә үзем...

Телгә килә:
әбиләр чуагы,
әбиләр чуагы...

*
* *

Ай тулысы —
күңлем ярсый,
ярсый инде.
Океаннарда,
диңгезләрдә
сулар ташый,
ташый инде,

Җансыз Айның
җанлы Җиргә
тәэсире
мине мәҗнүн
ясый инде.
Табигатьнең
кануны бер —
аңа барма
каршы инде.

Җәйге төн

Кышкы төн гади, беркатлы.
Кышкы төндә йокы татлы.
Җәйге төндә йокы кала,
аны ташлап йоклап кара!

Утырасың җәйге төндә
өй янында төнне тыңлап,
кыска төннең гаҗәп төрле
бар серләрен барлап:
Җәйге төннең йолдызлары
еракларга чакыруын,
тына белмәс сандугачның
күңелне ярсытып бер
җилкетүен,
тулган айның зиһеннәрне
чуалтуын,
кояш күзендә гади генә
нәрсәләрнең
гадилеген югалтуын,
чынга охшамаган
төнге күбәләкләрнең
кул яссуы яктылыкта
котырынып очынуын,

җәйге төннең сихрилеге
тәнеңә дә, җаныңа да
сыенуын...
Болар бар да аңлашыла.
Җәйге төндә ачылмаган
әллә ни бер нәрсә кала.

* * *

Сандугачлар төн буена
сайравыннан тынмады.
Күл өстендә төнбоеклар
йоклады.

Юләр булып, килмәдең,
матурлыкны күрмәдең.

Сын шикелле
ялангач ай
төн буена эшләде.
Күлмәк текте нурыннан —
Карамалар, зирекләр
көмеш күлмәк киделәр.

Алтын суы йөгерткән
мин дә кидем бер күлмәк.

Тик син генә белмәдең,
юләр булып, килмәдең,
чибәрлегем күрмәдең.

*
* *

«Сез үскәндә генә, кызым, апаң белән, рәхәт чагы булган гомернең»

Әнкәм сүзләре

Түгәрәк кенә, түгәрәк ике кыз,
әйтерсең лә пар йолдыз —
Ана күңелен яктырткан
төннәрен, кичен, көндез.

Икесендә пар толым.
Икесендә пар күлмәк.
Юллары уң булсын, дип,
ана теле пар теләк.

Кызлар үсеп җиткәннәр,
юлларын табып киткәннәр.
Уйдагы алга килгән —
киләчәктә көткәннәр.
Ә нигә соң ишетелә:
«Сез үскәндә генә, кызым, апаң белән,
рәхәт чагы булган дөньяның»...

Кыз бала

Бу кашларның кыйгачлыгы,
керфекләрнең озынлыгы,
куелыгы.
Алсу йөзнең уртасында,
кояш нурын биетүе,
эретүе.
Ике иреннең елмаюдан
тыелмавы,
йомылмавы.

Кына чәчнең хуш ис бөркеп,
дулкын булып йөгерүе,
    нелүе.
Ике күзнең нурга төреп,
уйнап-көлеп ук атуы,
    ут алуы.
Кыз баланы горур иткән
сыгылмалы зифа буе —
    кылыч йөзе.
Алтын көздә булыр туе.
«Учымда гына йөртәм»
дигәннең
каты булмасын ла кулы.

*
* *

> Бөтен кеше чибәр туган,
> мин генә чибәр түгел.

Язмышка үпкәләү кирәкми —
чибәр булып
яңадан туып була.

Мәхәббәттән исергәннәр
яңадан туа дөньяга,
чибәр булып.

Хатын-кызлар ана булгач,
яңадан туа дөньяга,
чибәр булып.

Иле өчен һәлак булган —
яңадан туа дөньяга,
чибәр булып.

. . . .

Нигә зарлар, аһ-ваһ килү?
Матурлыклар хисапсыз.
Сайлыйк берсен.

Син яңадан туып кара,
дөньяга туып кара,
чибәр булып.

*
*   *

Очар кош канаты
ике кашың —
рухың нык яшь башың.

Таммасын күзеңнән
яшең,—
очар кош канаты
ике кашың.

*
*   *

Бәхеттән
бер еладым.
Калган елау:
кайгыдан,
кайгыдан,
кайгыдан.

Күңел ярсый,
талпына,
килгәнмени
бәйгедән,
бәйгедән,
бәйгедән.

Җил дә давыл
таңыннан.
Тынлык килсә,
килә безгә —
гүя яшен
алдыннан.

«Гөлҗамал» көе

Тетрәндерә бу көйнең
күңелгә якынлыгы.
Тылсымы белән кабыза
җандагы ут-ялкынны.

Энҗе-мәрҗәннең яктыга
чыкмавы мөмкин түгел.
Кызлар язмышы һаман бер —
Сулкылдап сүнә күңел.

Кайда сез?

Ялкын-утларга бастырган,
сез, газаплар,
кайда сез?

Тынгысыз җан рухы булган,
сез, газаплар,
кайда сез?

Әллә утларда яндыгыз?
Сез, газаплар,
кайда сез?

Әллә суларда актыгыз?
Сез, газаплар,
кайда сез?

Әллә җилләргә тардыгыз?
Сез, газаплар,
кайда сез?

Сезне эзләргә чыгам —
Булсам иде чыдам.

*
* *

Шатлыклы көлүләр китерә,
мәхәббәт бәхетле итсә.
Коелып кына ага яшьләр,
сөйгән ярың өметне киссә.
Бер елавыңны кызганып,
хәсрәт алма син башыңа.
Күпме еласаң да ләззәт,
саф мәхәббәт хакына.

*
* *

Тән ярасы ала кеше.
Җелекләргә төшә сызлавы.
Тән ярасы авыр,
бик авыр.

Җан ярасы килә кешегә,
Бәгырьләргә төшә әрнүе,
Җан ярасы авыр,
артык авыр.

...Дулкын-дулкын булып
сузылып яңгырый
бер озын көй:
«...Хәсрәт эчләрендә хәсрәтләр күп,
Гыйшык хәсрәтеннән авыры юк».

Ялгыз калгач

Янында гел көлим әле,
еларммын ялгыз калгач.

Уйларымны онытып торыйм,
уйлармын ялгыз калгач.

Үпкәләүне күрсәтмимен,
вакыт бар — ялгыз калгач.

Үкенү имәсен башымны,
килер ул — ялгыз калгач.

Гомергә ялгыз калгач.

Нигә?..

Нигә килми бер җиңеллек?
Нигә мин генә
уйнап-көлмим?

Уйный да,
көлә дә
беләм бит.
Нигә соң уйда
гел мин?

Салган миңа тормыш
уен-гамен,
белсәм дә
уен ямен...

Яз

Ашыкмыйча, кичекмичә,
үз вакытында
быел тагын яз килде.

Яшь-җилкенчәк, җилкуарлар
ашкындылар:
«Тизрәк килсен, килеп җитсен!»
Алай дими эшкуарлар:
«Үтеп китсен, үтеп китсен.
Берүк кенә үтеп китсен!»

Беркемнең дә ай-ваена
карамыйча,
ашыкмыйча, кичекмичә,
үз вакытында
быел тагын яз килде.

Яз башында
кыеклардан, түбәләрдән
тама тамчы.
Тама-тама
төзәлде дигән яраны
быел тагын ачты.

Тып-тып тамган тамчы белән
янәшәдә
тамды җиргә күзнең яше.
Гөрләвектә кушылдылар
икесе бергә —
бусы аның ләйсән эше.

Зәңгәр күктә
шатлыгыннан
тәгәрәп-тәгәрәп кояш көлә.

Кыш көнендә
соры болыт артларында
безне сагынып интеккәндер,
кем белә?

Мәрхәмәтле кояш-табип
лазер-нуры белән
(җөйсез генә)
күңелдәге яраларны
тегеп куяр
үз вакытын
белеп кенә.

Без танышкан ай *

Апрельнең күк кичендә,
Гөрләвек йөгергәндә,
Ут-хисләр өлгергәндә,
Таныштык без бәйрәмдә.

Яз — Җирнең бәйрәме,
йөрәкләр бәйрәме.
Күңелнең хисләре —
чәчәкләр бәйләме.

Елмай, көл, йолдызым!
Елмай, көл, йолдызым!

Танышкан изге айны
җырга салып көйләргә,
уярга күңелләргә,
сагынып гел сөйләргә.

* Фәрит Шәрифуллин музыкасы.

Апрель син — безнең ай.
Син дәрткә, хискә бай.
Ашкынсын гомер-җыр,
гөрләвек шавыдай.

Елмай, көл, йолдызым!
Елмай, көл, йолдызым!

Бу гаҗәеп музыка

Бу гаҗәеп музыка! —
Диңгезләрне китерә
аяк йөзенә,
дулкынына кертеп
уйната.
Тыпырчынган җанны
җайга сала,
сабыйларны эретеп йоклата.

Бу дәһшәтле музыка!
Җанны бөеклеккә өнди,
җанга түбән уйлар килми,
кеше бөеклеген аңлый,
кеше кешелеген аңлый,
сынау килсә, сынмый,
җанда яну сүнми.

Бу гаҗәеп музыка!
Йөртә кояшлы аланда
гел якты уйлар белән.
Ләйсән яңгырга ияртеп,
яланаяк йөгертә.

Бу дәһшәтле музыка!
Давылларга алып керә,
утны-суны кичеп йөрисең,
утлы дулкын
бәреп ега,
тәмам беттем, диеп
уйлыйсың.
Әкрен-әкрен
яңа дулкын килә ярга,
шифа өрә
яраланган җанга.
Өмет дигән
дулкын килә.
Өметне бит,
син, музыка,
кисмисең?

Юк, юк!
Музыка өметне кисми!

Музыка — өмет канаты.
Музыка — ышаныч канаты.
Музыка — тормыш канаты.

Мең яшәсен музыка!
Бу гаҗәеп музыка!

Син биергә мине чакыр *

Сиңа гына карый күзем,
бетмәс кебек сөйләр сүзем.
Матур көйне көйләр идем,
ихлас сүзне сөйләр идем.

---

* **Шамил Шәрифуллин** музыкасы.

Син бул инде, егет, тапкыр:
син биергә мине чакыр.

Җилдән җитез әйләнербез,
алда безнең бәйрәмебез,
явар безнең ләйсәнебез,
килер ямьле җәйләребез.

Идәннәре нинди такыр,
син биергә мине чакыр.

Чәчләрне чәчкә бәйләрбез,
булырбыз пар чәчкәләр без.
Гөлләр үсәр, кырау тимәс,
салкын җилгә башын имәс.

Минем йөзем айдай балкыр,
син биергә мине чакыр.

*
* *

Кызлар гыйшкы матур чәчәк кебек —
ачыла ул уздырмый нәүбәтен.
Башны әйләндергеч исле әрем
хәтерләтә хатыннар мәхәббәтен.

Тал нечкә

Ай, күңел нечкә, күңел нечкә.
Ай, күңел нечкә, бигрәк нечкә.
Серләремне
уттан алып, суга салгач,
йөрәккәй түзә көчкә.

Ай, талым нечкә, талым нечкә.
Ай, талым нечкә, бигрәк нечкә.
Талны кочып,
сыгылып бер елыйсы иде, —
тал үзе түзә көчкә.

Сәрвиназ

Йомшак басып килә Сәрвиназ.
Һәрбер күзәнәге тулы наз.
Карашлары якты — зәңгәр яз.
Аны сурәтләргә сүзем аз.
Сыгылмалы гәүдәсенә ярашып,
җилләр исә, чәчен тарашып.
Күкнең, Җирнең сайрар кошлары
Озатып килә, кандаш җан табып.
Биеклеккә ашкан күңеле —
Ярсып очкан талмас коштай ул.
Хисе ташулы — берне сөяр,
бәхетенә илткән юлы шул.

Көтү

Көтү, көтү.
Иреңне көтү.
Балаңны көтү. Интегеп бетү.
Электән таныш хатын-кыз ирке:
Гомергә көтү, гомерлеккә көтү...

Берәмләп көтү, бөртекләп көтү.
Берегеп бетү, күнегеп бетү.
Киткәнне көтү, китсә дә — көтү.
Кайтаваз: китү, китү, китү...

Күз текәп көтү, онтылып көтү.
Тәрәзә бозын керфек эретү.
Яшь тә кушылгач, тынычлап китү —
Яңа көч сорый фидакарь көтү.

*
*   *

Диңгез кебек назлы итеп
беркем сөйли алмый.
Диңгездән дә дәһшәтлерәк
Беркем була алмый.

Шаяру

Исле гөлләр сибәр идем
алма бакчаларыңа.
Нинди бүләк бирим икән
йөрәк сакчыларыңа?

Бүләгемне алсыннар,
карап шаклар катсыннар,
уяулыкларын җуеп,
йөрәк бигең ачсыннар.

Йозаклары ачылды —
ачкычлары кулымда,
бер киртә юк юлымда.
Ә мин бераз шаярыйм,
ачкычны алып качыйм —
хәлеңне читтән карыйм.

*
*   *

Бушанып калган чакмы,
буш булып калган чакмы —
Уйлар йөри иләс-миләс,
ноктасына җитәр-җитмәс.
Яңа шатлык килер-килмәс,
кайгылары китер-китмәс.

*
* *

Кырык эшем кырылып китте.
Кырык эшем таралып бетте.
Кырыгы да кулдан төште.
Һич булмаса,
Яшь килми, күз коры.

Ә бүген менә,
бер мохтаҗга
ярдәм кулы суза алдым.
Күземнән яшь тәгәрәде —
шатлык нуры.

*
* *

Көзен сагышлар басамы?
Булмаганны!
Мәхәббәт баса көзен!
Алтын алмадай килешле —
карагыз, менә, йөзем.
Җиһанның туган көненнән
алма — сөю билгесе.
Шундый мәхәббәтле йөзләр
чолгаган тирә-юнем.
Көзге кояш, үртәгәндәй,
көлә бит кысып күзен.
Гел шул берәүгә тартылам
нигәдер көзен үзем.

Нигә бер көй көйләмисең, күңел?

— Нигә бер көй көйләмисең, күңел?
— Акыл белән йөрәгең дус түгел,
бер эзеңә төшә алмыйм һаман,
аккордтан ук көйдә ялгыш табам.

— Нигә миңа шундый авыр таләп?
Беләм. Үзем сугыштырам теләп.
Ут йөрәкнең салкын акыл белән
алышуы — изге көрәш, беләм.

Җирдә салкын бәрә, эссе суга,
сугышларга, нишлим, сәбәп чыга.
Шуңа әйтә алмыйм, күңлем — сагым,
булырмы бер эзгә төшкән чагың?

Кызлар чишмәсе

Чирмешәннең Кызылъярын тишеп,
агып чыга
көмеш чишмәләр.
Борынгыда туган үзләре,
борынгыдан килә көйләре.
Исемнәре матур:
«Сандугач чишмәсе», «Зәңгәр чишмә»,
«Кызлар чишмәсе»...
Мең серле бу чишмәләрнең
берәүсенең тик бер серен
сөйләп бирде Фатыйма әби.

«Кызлар җыены урыны булган ул чишмә,
хәзер сөйлим төп сүземне, тизме димә.

Бәхетле кызлар чишмәгә бага икән,
зәңгәр күзге аларны бигрәк чибәр иткән.

Кара язмыш көтсә әгәр берәр кызны,
чишмә ярсып, бәрә өскә салкын тамчы.

Бәхетле кыз көлә: суда уйный дулкын,
бәхетсезгә чишмә — гүя кара упкын.

Чирмешәннән ерак түгел, якын гына,
утырган авыл, сузылып чишмә ягына.

Бу авылда чибәр кызлар исәбе юк,
чибәрләрнең чибәре була, һич шик юк.

Чибәрләрнең дә чибәре — Сылу-Чибәр,
чибәрлеге тагын да йөз кызга җитәр.

Чибәр-Сылу чишмәнең бер серен белгән,
таң иртәдән үк ялгызы монда килгән.

Тәңре-Кояшның беренче кылыч-нуры,
төнне үтеп, сер-чишмәгә төшсә туры,

килүчегә гаҗәп тә нәрсә ачылган,
барасың таңда, кыю, тәвәккәл булсаң.

Чибәр-Сылу, аттан төшеп, җай тезләнгән,
кылыч-нурны каршыларга әзерләнгән.

Көтә кыз, чишмәдә бер тын әсәре дә юк,
шул чагында йөзеп килә якты бер ут.

Тын торган чишмә өсте куя чак селкенеп,
килеп чыга чишмәдән бер йолдыз-егет.

— Сине, Сылу-Чибәр, гомер көттем инде,
килдеңме, җаныем, әйдә киттек инде!

Егеткә карап шаккаткан Чибәр-Сылу,
ихтыярсыз бергә чума, тына су...

Кызны эзлиләр туганнар шау килеп,
Китәләр, атны алып, ай, мескен, диеп.

Еллар үтә...
Бервакыт Сылуны күрә ахирәте.
була имеш, нәкъ су анасы кыяфәтле.

Суга чума, кайда ул тану да белү.
Яңгырап кала тик чыңлап торган көлү.

Сылу-Чибәр китмәкче булган икән,
су егете юлыннан тыйган икән.

Сылу-Чибәр тудырган шул тик тамчылар...
Сылу-Чибәр тудырган шул тик ташкыннар...

Иреккә чыга елына тик бер мәртәбә,
язгы ташу аңа иреккә әйләнә.

Дулкын-дулкын килә икән төннәрендә,
яшь тамчысын коя ишек төпләренә.

Нигезләрне ялый, ярсып, елый-елый,
ташкынга бит ярдәм итеп булмый-булмый».

Сөйләп бетерде әби...
Чибәр-Сылу көлүе чишмәләргә таралган.
Чибәр-Сылу елавы чишмәләргә таралган.
Чибәр-Сылу сагышы чишмәләргә таралган.

Чирмешәннең яр астыннан
агып чыга
«Кызлар чишмәсе».
Бер тыңласаң —
көлә чишмә.
Бер тыңласаң —
җырлый чишмә,
Бер тыңласаң —
елый чишмә.

Якты шигырьләр

Бик күп мәкаләләрем минем «сугыштан соң» дип башланып китәләр. Саҗидә Сөләймановины да, Клара Булатованы да сугыштан соң очраттым. Поэзиядә минем өчен алар яңа исемнәр иде. Икесе дә талантлы, икесе дә хәзер татар совет поэзиясенә ныклап кереп калды. Яңа исемнәрне шулардан башлап китәсе килә. Бераздан, барыбызны да сөендереп, аларга Нурия Измайлова килеп кушылды. Ара бушап тормады, «биеклектә очрашу»га чакырып Асия Минһаҗева шигърият мәйданында калкып чыкты. Хәзер Бикә Рәхимова поэзиядә үз сүзен әйтергә җыена.

Бу шагыйрәләрнең барысыннан да бер фикер калды миндә. Хатын-кыз шагыйрәләрнең һәркайсының ир шагыйрьләрдән табып булмый торган үз хисләре бар. Алар мәхәббәтне бигрәк тә үзләренчә кичерәләр икән. Саҗидә Сөләймановаың иң көчле, иң усал шигырьләре — мәхәббәт шигырьләре. Нурия Измайлованы да юаш димәс идем. Бикә Рәхимова китабына «Сәрвиназ» исеме кушкан. Бик шигъри исем. Популяр җыр. Хатын-кыз күңеленең нечкәлеген тойган шагыйрь язгандыр кебек. «Сәрвиназ»ны укыгач, бездә наз җитмидер шикелле тоела миңа. Бәлки ул җыр яратканы өчен бу исемне алгандыр. Шамил Шәрифуллин белән бергә иҗат иткән бик матур җырлары бар. Бәлки шуңадыр. Шулай да бер төп хисне тотарга телим. Тыйнак, ялгыз кичерергә яраткан татар хатын-кызларының күңелләрен күрдем мин Бикә шигырьләрендә. Саҗидә усаллыгы әле запаста тора сыман. Авторның күңеле саф, шигырьләрендә якты җан яши.

СИБГАТ ХӘКИМ.

Август, 1985. Аккош күле.

ЭЧТӘЛЕК

I. Моң колачы

Алып Муса 5
Кошлар юлга артык әйбер алмый 6
Яшьлегемдә калам 7
Җайдак малай җыры 8
«Алтын капка»га баргач 9
Кырым җире 10
Дербент 12
Юлга чыксаң 13
Җиңел кулдан 13
«Син, хурлык...» 14
«Җир йөзендә...» 15
Балык чистартканда 15
«Ашыйсым килде...» 16
«Үз өлешен кызганмыйча...» 17
Моң колачы 17
«Җиргә генә ятып...» 18
«Галәмгә омтыламы кеше...» 19
«Тып-тын гына таң туды...» 19
«Кешеләрне мин кызганып...» 20
Әнием яшьлеге 20
Ленинград фронты. 1943 ел. Соңгы хат . . . 21
Яхшылык кылдыңмы? 22
«Кайчак артык тәмле сүзләр дә...» 22
«Баллы-татлының тәмнәрен...» 23
Балалар белән Кырлайга Тукай музеена бару . 23
«Бала күңеле — ак кәгазь...» 24
Бала-ана кайгысы 25
«Туганым абый — этием кебек...» 25
Төсләр 25
«Дер-дер килмәгез...» 26
Гаепләү 27
Үз урыны 27
Әгәр берәү 28
«Мәче-тычкан уены...» 28
Тәрәзәләреңдә ут яна...» 28

Алсын иде 29
Кызлар 29
«Бизәнә, хатын-кыз бизәнә...» 30
«Хатын-кыз өчен чит түгел...» 30
«Үсмер чакта, инде күптән...» 31
Сабан туе 31
Көз көнендә 32
Авылда иртә 33
Туган илгә кайттым 33
Әни каберен зиярәт итү 34
«Авылда җәйге кич — моңсулык...» 34
Әниләргә 35
Әкият дәвам итә 35
«Мәңгелеккә калу өчен...» 36
«Тормыш мине тарткалады...» 37
Сабырлык көче беләи 37
«Гомернең уртасы җитте...» 38
Җан тартмаса, кан тартсын 39
Поэзия логикасы — тормыш чынлыгы 39
Умырзая чәчәгенә 40

II. Ай яктысында язылган шигырьләр

«Энҗе тешләр...» 41
«Ай тулысы...» 41
Җәйге төн 42
«Сандугачлар төн буена...» 43
«Түгәрәк кенә, түгәрәк ике кыз...» 44
Кыз бала 44
«Язмышка үпкәләү кирәкми...» 45
«Очар кош канаты...» 46
«Бәхеттән бер еладым...» 46
«Гөлҗамал» көе 47
Кайда сез? 47
«Шатлыклы көлүләр китерә...» 48
«Төн ярасы ала кеше...» 48
Ялгыз калгач 49
Нигә? 49
Яз 50
Без танышкан ай 51
Бу гаҗәеп музыка 52
Син биергә мине чакыр 53
«Кызлар гыйшкы матур чәчәк кебек...» 54
Тал нечкә 54
Сәрвиназ 55

Көтү 55
«Диңгез кебек назлы итеп...» 56
Шаяру 56
«Бушанып калган чакмы...» 56
«Кырык эшем кырылып китте...» 57
«Көзен сагышлар басамы?...» 57
Нигә бер көй көйләмисең, күңел? 58
Кызлар чишмәсе 58
Якты шигырьләр. *Сибгат Хәким* 61

Бике Рахимова

(Файзуллина Минебике Рахматулловна)

САРВИНАЗ

Стихи

(на татарском языке)

Рецензенты **И. Ахунҗанов.**
Редакторы **Х. Әюпов.** Художнигы **А. Простов-Покровский.** Художество редакторы **Ф. Хәсьянова.** Техник редакторы **Ф. Абдрахманова.** Корректоры **Х. Фәйзерахманова.** ИБ № 4278.

Наборга бирелде 27.08.85. Басарга кул куелды 19.12.85. ПФ 09209. Формат 70×90 1/32. Типография кәгазе № 1. Гарнитура школьная. Печать высокая. Якынча басма табагы 2,3. Усл. кр. отт. 2,4. Учетн.-изд. табагы 2,3. Заказ Ф-393. Тираж 2000. Бәясе 10 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420084, Казань, ул. Баумана, 19.

Типография издательства Тат. ОК КПСС г. Казань, ул. Декабристов, 2.

10 тиен